РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«06» февраль 2020 с. Тюлячи № 48

Педагогик хезмәткәрләргә - Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне бирү Тәртибен раслау турында

«Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ 2020 елның 24 гыйнварындагы 20 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү турында» карары нигезендә һәм педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында педагогик кадрларны беркетү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Педагогик хезмәткәрләргә - Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне бирү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланган
"06" 02 2020 № 48

Педагогик хезмәткәрләргә - Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип педагогик хезмәткәрләргә - Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә (алга таба - оешма) эшләүче яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүнең күләмен һәм бирү тәртибен билгели.

2. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән башкарыла.

3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр - яшь белгеч дип 30 яшькә кадәрге, көндезге бүлектә һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын беренче тапкыр тәмамлаган, югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура программалары (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирүче мәгариф оешмасы) буенча дәүләт аккредитациясе булган һәм һөнәри белем бирү һәм квалификация дәрәҗәсе нигезендә югары белем бирүче мәгариф оешмасын яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасын тәмамлау елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча хезмәт шартнамәсе буенча оешмага эшкә кабул ителгән.зат танила.

4. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда бирелә:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмалары;
- гомуми белем бирү оешмалары;
- өстәмә белем бирү оешмалары.

5. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү педагог вазифасында өч ел өзлексез эшләү дәверендә эшкә урнашу датасыннан билгеләнә.

Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар Оешма боерыгы белән раслана.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү алу өчен эшкә урнашу вакытын үткәрүнең мөһим сәбәпләренә түбәндәгеләр керә:*

- документлар нигезендә расланган, вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча вакытлы хезмәт үтү яки альтернатив граждан хезмәте үтү;

- йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, бала карау буенча отпуск балага өч яшь тулганчы.

Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләнергә мөмкин, әгәр педагогик хезмәткәр-яшь белгеч хезмәт мөнәсәбәтләрен вакытлыча эшкә яраксызлыгы вакыты беткәннән соң, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакыру буенча вакытлы хезмәте, яки альтернатив гражданлык хезмәте узу вакыты тәмамланганнан соң йөклелек һәм бала табу буенча отпуск вакыты,3 яше тулганчы бала карау буенча отпуск беткәннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерсә.

7. Хезмәт килешүе туктатылган очракта, хезмәткәрне хәрби хезмәткә чакыру яки аны алыштыра торган альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрү белән бәйле рәвештә ай саен бирелә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү, педагогик хезмәткәр - яшь белгеч Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакыру буенча вакытлы хезмәт үтү яки альтернатив граждан хезмәте узу тәмамланган көннән алып 60 көннән дә соңга калмыйча, өч ел эшләү чорында яңадан билгеләнергә мөмкин.

8. Педагогик хезмәткәрләргә - Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы яшь белгечләргә ай саен өстәмә түләүне туктатып тору түбәндәге вакытларда туктатып торыла:

- йөклелек һәм бала табу буенча отпуск , бала карау буенча отпуск балага өч яшь тулганчы;

- көндезге формада аспирантурада уку.

9. Педагогик вазыйфага башка Оешмага күчкәндә, 30 көннән дә артык булмаган вакытка эш тәнәфесләре рөхсәт ителә.

10. Санның яки штатның кыскаруына бәйле рәвештә педагогик хезмәткәрне яшь - белгечне эштән чыгарганда, яисә чираттагы педагогик вазыйфага эшкә урнашканда, 60 көннән дә артык булмаган вакытта эштән китү рөхсәт ителә.

11. Педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән расланган. Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасының 1 бүлегенең 2 пункты нигезендә педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларына карап билгеләнә.

12. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү педагогик хезмәткәр - яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

13. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү төп педагогик вазифа һәм педагогик вазифа буенча билгеләнә, аның буенча эш әлеге педагогик хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында гамәлгә ашырыла.

14. Педагогик хезмәткәрләргә - атнага (елга) хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D=P\times H_f/H_n$$

биредә:

D - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә - хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) сәгатьләр нормасы билгеләнгән, әмма аенаайлык өстәмә түләүнең күләме 1111 сумнан артмый;

P - педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә атнага (елга) педагогик эш сәгате нормасы өчен 1111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

$H_f$- педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

Hn -хезмәт хакы базасы ставкасы өчен сәгать нормасы.

15. Педагог хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме (педагогик хезмәткәрләрдән - яшь белгечләрдән тыш - айлык стимуллаштыручы өстәмә күләме әлеге Тәртипнең 12 пунктында билгеләнгән) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D=P\times t$$

биредә:

D - педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләү күләме, әмма аена 1111 сумнан да артмый торган;

P - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә хезмәт хакы ставкасы өчен 1111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

t - факттагы эшләнелгән вакыт (ставкалар).

16. Педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр хисабына бирелә.